**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының**
**Ивашкино авыл җирлеге Советы**

# К А Р А Р

17 июнь 2025 ел № 159

**Бишенче чакырылыш**
**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының**
**Ивашкино авыл җирлеге Советы депутатларын**
**сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Ивашкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ивашкино авыл җирлеге Советы **карар кылды:**

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ивашкино авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» («Наш Черемшан») газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

Ивашкино авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Андреев Ф.П.